ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы, 422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.11.2024 с. Кильдеево 4

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 26 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уланово авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Уланово авылы клубында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Уланово авылы, Заозерная урамы, 44 йорт 10.00 сәгатьтә.

4. Җыенны оештыручы итеп Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин